КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 21 март г.Казань № 164

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бөртекле культуралар җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 836 нчы карары белән расланган Бөртекле культуралар җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен бөртекле культуралар җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бөртекле культуралар җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 836 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 27 июнь, 608 нче, 2022 ел, 21 октябрь, 1130 нчы, 2022 ел, 11 ноябрь, 1204 нче, 2023 ел, 20 март, 279 нчы, 2023 ел, 29 май, 649 нчы, 2023 ел, 5 декабрь, 1561 нче, 2024 ел, 5 апрель, 232 нче, 2024 ел, 14 ноябрь, 1004 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Бөртекле культуралар җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен бөртекле культуралар җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

18 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Сайлап алуны уздыру турында игъланга үзгәрешләр кертү Министрлык тарафыннан әлеге Тәртипнең 19 пунктында каралган сайлап алуны уздыру турында игъланны формалаштыру тәртибенең шундый ук тәртибендә, заявкаларны кабул итү

тәмамлану датасына кадәр, түбәндәге шартларны үтәп, гамәлгә ашырыла:

заявкаларны бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән заявкаларны кабул итү датасына кадәр әлеге срок кимендә өч календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр керткәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, заявкалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә сайлап алуда катнашучыларның әлеге Тәртипнең 31 пункты нигезендә заявкага үзгәрешләр кертү хокукы каралган нигезләмә кертелә;

заявка биргән сайлап алуда катнашучыларга, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр итә.»;

25 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча, күрсәтелгән документларны теркәп, товарның иярчен документын рәсмиләштерү кагыйдәләре нигезендә рәсмиләштерелгән ашлык партиясенә яки ашлык эшкәртү продуктлары партиясенә товарның иярчен документлары белән раслана торган, сайлап алу үткәрү турында игъланда үз җитештерүендәге бөртекле культураларны реализацияләү фактын раслый торган документлар реестры (шартнамәләр, товар-транспорт накладнойлары һәм (яки) универсаль тапшыру документлары, реализацияләнгән продукцияләүгә түләүне раслый торган түләү йөкләмәләре);»;

39 һәм 40 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле $44^1$ пункт өстәргә:

«$44^1$. Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, үзгәрешләр кертү сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге беркетмәнең яңа версиясен булдыру юлы белән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең беренче версиясенә имза куелган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

45 пунктта «төзәтергә мөмкин» сүзләрен «төзәтә» сүзенә алмаштырырга;

50 пунктта «яисә заявкасы җиңүче дип танылган соңгы сайлауда катнашучы заявкасыннан соң кимү тәртибендә чираттагы рейтингы булган сайлап алуда катнашучы белән килешү төзи» сүзләрен төшереп калдырырга;

51 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

54 пунктның беренче абзацында «субсидия бирү» сүзләреннән соң «йә субсидия бирүдән баш тарту» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин